СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

15 МАРТ, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 29 (8041) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## Иртәгә - сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм торак - коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре көне

## Бәйрәмегез белән!

Кадерле иптәшләр! Ел саен мартның өченче якшәмбесендә сез, сәүдә, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм торак - коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре, үзегезнең һөнәри бәйрәмегезне билгеләп үтәсез. Шул уңайдан чын күңелдән котлауларыбызны кабул итегез.

Дистәләгән еллар эчендә сезнең коллективлар зур үсеш юлы үтте. Сезнең тырыш хезмәтегез нәтиҗәсендә предприятиеләрнең матди - техник базасы сизелерлек ныгыды, халыкка хезмәт күрсәтү белән бәйле байтак проблемалар уңай хәл ителә, аларны халык куллануы товарлары белән тәэмин итү оештырыла, хезмәт күрсәтүнең яңа төрләре үзләштерелә.

Бүген, базар мөнәсәбәтләренә күчү чорында, сезгә катлаулы шартларда эшләргә туры килә. Бу оперативрак эш йөртергә, үзара отышлы яңа контрактларга керешергә, ихтыяҗ нигезендә хезмәт күрсәтү һәм продукция төрләрен үзләштерергә, базарны өйрәнергә мәҗбүр итә.

Сезнең алда халык ихтыяҗлары һәм проблемаларын канәгатьләндерү белән бәйле зур һәм киеренке эш тора һәм без сезнең аны уңышлы башкаруыгызга ышанабыз.

Бәйрәм көннәрендә без сезнең барыгызга да сәламәтлек, бәхет, Октябрь районы халкы өчен башкарыла торган барлык эшләрегездә һәм башлангычларыгызда уңышлар телибез.

**Ф.СИБАГАТУЛЛИН,**
**халык депутатларының район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы.**



Таныш булыгыз: Норлат тимер юлчылар эшчеләрне тәэмин итү бүлеге сатучысы Гүзәл Шәрифуллина. Сәүдә училищесын тәмамлаганнан соң икенче елын гына эшләсә дә, ул ОРСның тату коллективында үз урынын табарга, сатып алучыларның мәхәббәтен яуларга өлгерде инде. Ә эш урыны бик игелекле Гүзәлнең: шәһәрлеләргә данлыклы тимер юлчыларның күпереп пешкән икмәк - булка әйберләрен сата ул. Эш урыны һәрчак тәртиптә, үзе мөлаем, ачык йөзле була.

***НГДУның эшчеләрне тәэмин итү бүлеге (ОРС)- шәһәрдәге иң эре сәүдә оешмаларының берсе. Төп бурычы - нефтьчеләрне кайнар аш белән тәэмин итү аның. Бүлектәге 19 казан пункты, шул исәптән стационар дүрт ашханә дә шул бурычны үти. Болардан тыш 12 сәүдә ноктасы бар. ОРС дүрт балалар бакчасы, дүртенче мәктәп, НУРБ санаторий - профилакториена да хезмәт күрсәтә.***

***ОРСның 1997 нче елга планнары нинди? Бүлек начальнигы В.Н.ХУҖИНАГА без шул сорау белән мөрәҗәгать иттек. Ул түбәндәгеләрне сөйләде:***

## ТЫРЫШСАҢ БУЛА ИКӘН

- Алдагыларыннан күпкә катлаулы һәм авыр булган, безне һәрьяклап сынаган 1996 нчы ел артта калды. Иң мөһиме, без ничек булдыра алсак шулай икътисади кризисны җиңеләйтеп, коллективны саклап кала алдык. Ә соңгысының бүгенге көндә әһәмияте аз түгел.

Хәзер безнең төп бурычыбыз - товар әйләнешен арттыру, халыкны кирәк булган товарлар белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин итү. Бүлектә яңа эш урыннары булдыру да беренче планда кала. Билгеле инде, бүгенге көндә производствога яңалыклар кертеп, аны даими рәвештә камилләштерә бармасаң, «агымда» барып булмый. Шуны истә тотып, без дә «Огонёк» кибетендә реконструкция эшләре алып барабыз. Аның беренче катында ит, сөт һәм балык продуктлары сатылачак. Шунда ук компактлы гына бер кафетерий да булачак. Икенче катта исә кондитер әйберләр, азык концентратлары реализацияләнәчәк. Сатучыларны бригадага бүлү булмаячак: кибеттә бер генә коллектив эшләячәк. Кибет заманча дизайнлы булыр. Дружба урамындагы һәм «Каенкай» ашханәсе янындагы «Ләйсән» сәүдә вагончыклары да реконструкцияләнәчәк. Һәр икесендә дә азык - төлек сатылачак бу нокталарда 4 яңа эш урыны барлыкка килгән.Шундый нокталарның тагын берсе НУРБның промышленность базасында эшли инде.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

## Аларда - кеше кайгысы

Районның күптармаклы производство предприятиесенең торак - коммуналь хуҗалыгы коллективы быел профессиональ бәйрәмен яна, элеккегедән ике тапкырга якын зуррак составта каршы ала. Предприятиедә элек 170 кеше исәпләнгән булса, бүген НГДУ торак - коммуналь хуҗалыгы кушылгач 320ләпкә җыела. Әлбәттә, исәпсез - хисапсыз проблемалар, мәшәкатьләр белән тулы предприятие коллективы өчен ведомство карамагындагы торак фонды, алар белән бергә суүткәргеч, канализация челтәрләре, чистарту корылмалары бер кул астына күчкәч җаваплылык та икеләтә арткандыр. Һәр участокта авария - диспетчерлык хезмәте, автотранспортчылар, йорт идарәсе, шәһәрне төзекләндерү, ремонт - төзелеш участогы, чистарту корылмалары, мунча һәм кунакханә булсынмы, эшне җиренә җиткереп алып барырга тырышалар. Гомумән алганда, керемнәр буенча җитештерү планы 95,5 процентка үтәлгән. Аерым алганда үткән елда суүткәргечләр буенча эшләү, шәһәрне санитар чистарту, кунакханә хезмәте предприятие өчен керемле була. Торак фондына үз көчләре белән 253 миллионга якын сумлык капиталь ремонт үткәрәләр. План буенча бу дәрәҗәдән күпкә (1 миллиард сумга) артыграк эш башкарылырга тиеш булган, әлбәттә, ләкин район бюджетында бу максатларга акча бүленмәве капиталь ремонтка зур тоткарлыклар тудыра.

Бәйрәм алдыннан аеруча предприятиенең ремонт - төзелеш участогы әйбәт күрсәткечләр белән килә. Торак фондын, предприятиенең матди базасын төзекләндерү тулысынча алар җилкәсендә. Хәзер ишекләр, тәрәз рамнарын үзләре ясыйлар. Биредә бик уңган балта осталары Исламнур Гыйльфанов, Хафиз Лотфуллин, Таһир Ибәтуллин тырышып эшлиләр.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

*30 мартта — сайлау*

## Уртак фикер белән

**13 март көнне район хакимияте башлыгы, 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округы буенча Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат Фатих Сәүбән улы Сибагатуллин Мичурин исемендәге КХАның Урта Камышлы бригадасы механизаторлары белән очрашты.**

Әңгәмә җылы дустанә атмосферада барды. Хакимият башлыгының районның социаль - икътисадый үсешендә төп моментлар, киләчәккә планнар, авыл хуҗалыгын үзгәртеп кору буенча хәлиткеч адымнар турындагы чыгышын механизаторлар зур кызыксыну белән тыңладылар, сораулар бирделәр. Фатих Сәүбәновичның мичуринлыларга аерым сүзе дә бар иде.

- Сез районда ышанычлы әйдәп баручы хуҗалык, - диде ул һәм ары таба да ныклы хуҗалык итү өчен тәҗел булган алшарт турында сүз башлады. Аның төп асылы - хуҗалык исәбе белән эшләүче аренда звенолары. Чыгымнарга каршы механизмны эшкә җигеп, продукция җитештерүне арттыру, аның үзкыйммәтен киметү, авыл кешесендә хуҗа булу хисен уяту - уңышлы нәтиҗәне тәэмин итәчәк төп шартлар. Мичуринлылар хуҗалык итүнең күмәк кооперативлар формасы буенча эшлиләр. Әлеге элементлар аларга бары файдага гына булыр иде.

- Без каршы түгел, эштән курыкмыйбыз, - диделәр механизаторлар хакимият башлыгы тәкъдименә җавап итеп.

Чыннан да, узган ел үз җирләреннән 36шар центнердан артык уңыш үстергән игенчеләрнең тырышлыгы бәхәссез. Быел алар икеләтә омтылыш белән эшлиләр. Ел башыннан хуҗалыкта терлекчелекне асрау технологиясен камилләштерү белән бергә игенчелек технологиясен үзгәртүгә дә әзерлек бара. Хәзер төп көч язгы чәчүгә әзерлеккә юнәлтелгән. Механизаторлар авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлап бетерделәр, хәзер 3 бригадада да агрегатлаштыру бара. 1 апрельгә тракторларны да тулысынча әзерлек сызыгына куячаклар. Хәзердән 7 орлык төягеч, 3 ашлама төягеч ясалды, соңгысын тагы 2не өлгертергә җыеналар. Сыйфатлы орлык, мулдан тупланган минераль ашлама (ул 2 мең тоннага җиткереләчәк), җир белән эшләүдә төгәл таләпләрне үтәү, агротехника нигезендә хуҗалык быел уңышны гектарыннан 50 центнерга җиткерергә җыена.

Хакимият башлыгы хуҗалыктагы бу омтылышны хуплап билгеләп үтте. Очрашу уртак фикер - яңалыкны куллануудан курыкмаска һәм авыл кешесенең эш өчен януын. хуҗа булу тойгысын уятырга, бер сүз белән әйткәндә, яхшырак яшәү өчен яхшырак эшләргә дигән ният белән төгәлләнде.

## Шәхси хуҗалык - өстәмә чыганак

**Быелның ике аенда шәхси хуҗалыклардан сөт сатып алу турында мәгълүматлар.**

**Саннарның беренче баганасы - ике айда хәзерләнгән сөт ( центнерларда), икенчесе - беренче квартал заданиесенең үтәлеше (процентларда)**

Быел индивидуаль сектордан сөт сатып алуны оештыруга тиешле әһәмият бирелүнең нәтиҗәсе күз алдында - узган ел ике ай ярым чамасы вакыт эчендә шәхси хуҗалыклардан нибары 47тонна сөт җыелган булса, быел сатып алынганы 220 тоннага җитте инде. Шунысын да әйтергә кирәк, гыйнварда һәм февральдә җыелган сөт 80 - 83 тонна булса, мартның ике атнасында 57 тонна продукция сатып алынды. Бу көннәрдә сөт - май комбинатына көн саен халыктан җыелган 5 - 6 тонна продукция китерелә.«Комбайн», «Заветы Ильича», «Алга», «40 лет Победы» хуҗалыкларыннан соңгы вакытта продукция аеруча күп килә. Башка хуҗалыкларның да күбесендә бу эш игътибар үзәгендә. Ә менә «Таң», «Сөлчә» хуҗалыкларыннан ике - өч атна инде продукция кергәне юк. Халыктан сөт җыюда гомер - гомергә башкаларга үрнәк булган Югары Норлатта да бу эшкә игътибар сизелми.

| | | |
|---|---|---|
| «40 лет Победы» | 252 | 137 |
| «Татарстан» | 178 | 102 |
| «Заветы Ильич» | 128 | 79 |
| «Комбайн» | 147 | 62 |
| М.Җәлил исем. | 49 | 36 |
| Мичурин исем. | 92 | 35 |
| Әлмәт | 63 | 30 |
| Киекле | 60 | 27 |
| «Алга» | 61 | 26 |
| «Чирмешән» | 67 | 25 |
| «Заря» | 25 | 25 |
| «Чишмә» | 35 | 23 |
| «Правда» | 23 | 23 |
| Хафизов исем. | 89 | 21 |
| Синдряков исем. | 76 | 21 |
| «Таң» | 17 | 17 |
| Кузнецов исем. | 47 | 15 |
| «Кондырча» | 42 | 15 |
| «Рассвет» | 27 | 15 |
| «Москва» | 9 | 15 |
| «Игенче» | 33 | 14 |
| «Якты күл» | 25 | 14 |
| «Төрнәс» | 24 | 13 |
| «Родина» | 13 | 9 |
| «Мамык» | 12 | 8 |
| «Восход» | 8 | 8 |
| «Строитель» | 20 | 7 |
| «Үрнәк» | 9 | 4 |
| «Сөлчә» | 3 | 2 |
| **Район буенча** | **1634** | **27** |

Шәхси хуҗалыклардан сөт җыюның продукция хәзерләү күләмен арттыру белән бергә халыкка азмы - күпме акча чыганагы булуын да онытмаска иде.

## Иртәгә - сәүдә, көнкүреш хезмәте күрсәтү һәм торак - коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре көне

# ТЫРЫШСАҢ БУЛА ИКӘН

( Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Кулинария әйберләре белән сату итүче бу объектта ике кеше эшли. Шашин урамындагы кечкенә кибет тә әлеге микрорайонда яшәүчеләрнең ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерер дип өметләнәбез. Тулаем алганда, быел без яңа 20 эш урыны булдыруны планлаштырдык. Шуның 10сы сәүдә нокталарында, тагын шул кадәрлесе җәмәгать туклануы объектларында. Бу - аерым кибетләрне озайтылган эш режимында эшләүгә күчерүгә дә мөмкинлек бирәчәк. Мисал өчен, Совет урамындагы 183 нче йорттагы кибетебез әлегәчә кичке тугызга кадәр эшли иде, апрель аеннан исә ул кичке унга кадәр сәүдә итәчәк. Ә биредә барлык төр азык - төлек продуктлары, аракы - шәраб әйберләре сатылачак. Кичке вакыт дигәннән, «Яшьлек» кафесын көндез дә, кич тә эшли торган итмәкче булабыз. Көндез ул гади кафе ролен үтәсә, кич яшьләр җыелу урыны булып хезмәт итәчәк, шулай ук төрле кичәләр үткәрү дә мөмкин булачак. Шуңа да аны заманча итеп үзгәртү өчен якын көннәрдә бинага реконструкция үткәрелә башлаячак.

Җәмәгать туклануы объектлары өчен яшелчәне дә үзебез үк үстерергә ниятлибез. Безнең бу юнәлештә азмы - күпме тәҗрибәбез дә бар инде. Узган ел 6 гектарда бәрәңге үстердек. Билгеле, бу культура астына мәйданны 10 гектарга җиткерергә исәплибез. Чөгендерне дә үзебез үк хәзерләргә планлаштырабыз.

Гомумән, заманалар никадәр авыр дип еш зарлансак та, бүгенге көн үзенчә кызыклы да дияр идем әле мин. Иң элек мөстәкыйльлек, эзләнеп, сайлап эшләү мөмкинлеге белән. Бу безнең төп багъланышыбыз - халыкны кирәкле товарлар белән тәэмин итү бурычын үтәү өчен дә чикләнмәгән мөмкинлекләр тудыра.

Форсаттан файдаланып, барлык сәүдә хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлап, аларга хезмәтләрендә уңышлар, гаилә бәхете һәм... сатып алучылар мәхәббәте теләр идем.

**Р.ГИНЯЕВА**
**язып алды.**

# Заман агышына яраклашып

Машина төзү заводы коллективы электән үк профессиональ бәйрәмнәрен коммуналь хуҗалык хезмәткәрләре белән бергә бәйрәм итә иде. Анысы предприятиенең шул ук министрлыкка каравыннан. Завод күп еллар буе су чистарту җайланмалары чыгарып килде. Ә менә соңгы елларда ул җитештерү офыкларын киңәйтте: авыл хуҗалыгы өчен яңа төр продукция - культиваторлар җитештерүне җәелдереп җибәрде. Бүгенге көндә производство халыкка газ кертү эшләреннән тыш тулысынча шуңа җайлаштырылды. Предприятие директоры Ю.М.Жемков әйтүенчә, бүгенге көндә язгы чәчүгә районның һәр хуҗалыгы өчен бер җайланма әзер диярга мөмкин.

Коллектив зур кыенлыклар белән булса да яңа икътисади шартларга яраклашырга тырыша: продукция җитештерүдә, исәп - хисап ясауда яңа ысуллар эзли. Соңгылары нигездә бартер буенча хәл ителгәнгә, предприятиедә маркетинг бүлеге оешты, кибет ачылды - анда башлыча бартер юлы белән килгән әйберләр эшчеләргә хезмәт хакы исәбенә бирелә. Хәер, предприятие җитәкчелеге эшчеләргә хезмәт хакын да үз вакытында түләргә тырыша.

Нинди генә катлаулы шартларда да хезмәтләре белән тырыш, үз эшләрендә абруйлы белгечләр коллективның горурлыгы, куанычы булып кала бирә. Рәсемдә шундыйлардан Анатолий Салмин һәм Николай Кочетковны күрәсез. Анатолий заводта югары квалификацияле электр белән эретеп ябыштыручы, ә Николай инструменчы - слесарь булып дистә елдан артык эшлиләр.



Шул елларда тупланган тәҗрибәләренә таянып җитәкчелек аларга иң җаваплы эшләрне тапшырып килә.

Бүген Норлат машина төзү заводында эшлекле атмосфера: станоклар гөрелтесе, ябыштыру аппаратлары тавышы астында аерым - аерым һәркем кулы белән башкарылган кечкенә генә эшләрдән 120 ләп кешелек коллективның тулаем хезмәт җимеше туа.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## ЭШЛӘРЕННӘН КАНӘГАТЬ

Юынырга гел шәһәр мунчасына йөрибез без. Тырыш, бердәм коллектив эшли биредә. Үз вазифаларын намус белән үтәп, халыкка хезмәт күрсәтүче ул кешеләрне һөнәри бәйрәмнәре белән котлап, аларга тазалык - саулык, эшләрендә уңышлар телисе килә.

**М.ЖУКОВ.**
**Норлат шәһәре.**

# Аларда - кеше кайгысы

( Ахыры. Башы 1 нче биттә).

МППның профсоюз комитеты рәисе Наил Мирзанов әйтүенчә, кунакханә администраторы Нина Сидорованы, шоферлар Анатолий Васильев, Рафик Усманов, ике дистә елга якын чүп җыючы машинада эшләүче Анатолий Мокин, тракторчылар Николай Соловьев һәм Илшат Хәсәнҗанов, себерүчеләр Мария Латышева, Роза Никматулова, шәһәрне төзекләндерү буенча мастер Валентина Евлентьева, авария хезмәте эретеп ябыштыручысы Ирек Хамматов, слесарь - сантехник Сергей Петров предприятиедә аеруча зур мактауга лаек эшчеләр.

Дөрес, коммуналь хуҗалык халык тарафыннан гомер - гомергә канәгатьсезлек белдерелә торган тармак булып санала. Бу шулай да - йортта эш бетмәгән кебек, шәһәрдә дә бер җирне «ямыйсың» гына, икенчесе көтеп тора, чөнки бу кешенең көндәлек ихтыяҗын кайгырта торган тармак: өйләргә җылы киләме, халык суга тилмерммиме - һәммәсен игътибар үзәгендә тоту мөһим. Болар коммуналь хуҗалыкның «йөрәге» - диспетчер Әлфия Минәхмәтовна Әбҗәппаровага (рәсемдә) бик якыннан



таныш: нәкъ ул клиентларны - борчуы, зары тулып килгән яки шалтыраткан халыкны предприятие белән бәйли торган бер буын диярга мөмкин.

- Һәркем белән уртак тел табарга, үтенечен кичектермичә үтәргә тырышасың,- ди ул. - Төрлесе була, телефоннан «матур» сүзләр ишетергә, килеп өстәл каккан да тынычлык сакларга туры килә. Ләкин безнең эштә килеп чыккан тоткарлыклар эшчеләребез аркасында түгел, ә башлыча запас частьләр булмаудан яки башка матди сәбәпләрдән туа. Югыйсә, эшчеләр, бигрәк тә шоферлар, тракторчыларның хезмәте тулы энтузиазмга нигезләнгән, чөнки хезмәт хаклары бик аз. Шуңа карамастан, аларга күп вакыт көнне төнгә ялгап эшләргә туры килә.

Хәер, Әлфия Минәхмәтовна өчен предприятие үзе дә икенче өйне алыштырган диярга була: тәүлекнең теләсә кайсы вакытында диспетчерны урынында күрергә мөмкин. Коммуналь хуҗалык хезмәткәрләренең профессиональ бәйрәмен алар гаилә белән каршылыйлар, чөнки ире Рафик Мингәрәевич та биредә ике еллап шофер булып эшли...

Хезмәтегез халыкка да, үзегезгә дә шатлык китерсен - моңысы күптармаклы производство идарәсе хезмәткәрләренең барчасына да профессиональ бәйрәмнәре уңаеннан әйтәсе килгән теләк.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

# БАЗАРНЫ МАКТА, АТЕЛЬЕГА ЙӨР

Без Өммегөлсем ханым белән химик чистарту пунктында очраштык. Авылда механизатор булып эшләүче иренең мех курткасын чистартырга алып килгән иде ул. Шунда ук улының чистартылган кышкы пальтосын да алды.

- Шөкер, бик әйбәт булды әле. Олысына кечерәйде, кечесенә исә таман гына була,- диде ул яхшы итеп чистартылган пальтоны әйләндереп карап,- гаиләм ишле, барысына да яңаны җиткезеп булмый шул.

Анысы шулай. Хезмәт хакың очны очка ялгап барырга җитмәгәндә кайда инде ул яңа кием юнәтү?

- Бу цех зур зыян белән эшли. Әмма шәһәргә химик чистарту пунктыннан башка мөмкин түгел, кыйммәткә төшереп булса да чистарту средстволарын юнәтеп, пунктны эшләтү чарасын күрәбез,- диде безгә идарәнең баш икътисадчысы М.А.Маркова. - Гомумән, халыкның аз тәэмин ителешле катламы өчен эшлибез без.

Анысы шулай инде. Кесәң тулы акча булганда ательега заказ биреп күлмәк тә тектермисең, үкчәсе төшкән аяк киемеңне дә төзәттереп изаланмыйсың. Ә мондый мөмкинлегең булмаса? Билгеле инде, көнкүрешчеләргә мөрәҗәгать итәсең. Әнә, 8 Март алдыннан Модалар ательесы продукциясенә заказ күпме булды. Альяпкычлар, кухня «чүпрәк - чапракларын» тиз алып бетерделәр. Биредә гади тукымадан тегелгән халатлар 37, фланельдән тегелгәннәре 47 мең сум гына тора иде бит. Бүген базарда инде мондый бәяләргә шундый халатларны, кем әйтмешли, шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Өстәвенә, сыйфатлары да базардагыдан күпкә яхшырак. Алай булса, товар ни өчен арзан дип әйтүегез дә бар. Эш шунда ки, соңгы вакытта идарә тукымага сәүдә өстәмәсе ясамый. Иң мөһиме, тегелгән товар сатылсын да, ательедагы тегүчеләр өчен эш фронты булсын.

Йон теттерү цехы да халык мәнфәгатьләрен беренче планга куя. Менә инде берничә ел рәттән монда эш өчен бәянең үскәне юк. Биредә 1 килограмм йон эшкәрткән өчен 3 мең сум алсалар, Богдашкинода шундый ук эш өчен ике тапкыр күбрәк сорыйлар.

Ә чәчтараш? Теге заманаларда ничек 22 мастер эшләсәләр, коллектив бүгенгәчә шул составта. Клиентлар саны да кимеми. Чәчтараш кызлар ай саен предприятие кассасына 19 - 20 миллион сум выручка кертеп торалар.

Аяк киеме төзәтү, көнкүреш техникасы ремонтлау цехларын тоту никадәр генә зыянга төшсә дә, җитәкчелек аларының нормаль эше өчен дә шартлар тудыра. Урта хәлле гаиләнең «котырган» акча таләп итүче өйдәге осталарга мөрәҗәгать итәргә мөмкинлеге булмаса кая барсын? Билгеле инде, бирегә. Ни дисәң дә, биредә бәяләр сизелерлек түбән, өстәвенә, эш өчен гарантия дә бирелә.

Их, җәмәгать, көнкүреш хезмәтенең гөрләгән чаклары бар иде. Заманында тире эшкәртү цехына якын килмәле түгел иде. Кабул итүче 2 - 3 ай алга заказлар кабул итә иде. Юк шул, сарык тиресеннән тегелгән туннар модада түгел хәзер: базар конкуренциясе аларны прилавкалардан «кысып» чыгарды. Тегү ательесы продукциясенә дә сорауның кимүенә базар сәбәп. Шулай булса да район халкына көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсе (хәзер товар җитештерү һәм хезмәт күрсәтү буенча «Надежда» дәүләт предприятиесе), үзенә кыенлык тудыру бәрабәренә булса да, «җан» сакларга тырыша (ә бит республика күләмендә үзләрен үзләре саклап калган шундый идарәләр бармак белән генә санарлык). Хәзер биредә 13 цех бар. Шуларның өчесе: йон теттерү, фото һәм чәчәк ясау цехлары гына табышка эшли. Заманында идарәнең авылларда 30лап комплекслы кабул итү пункты бар иде. Хәзер аларның саны бер дистәдән аз гына артык. Аларында идарәдә җитештерелгән продукцияне сатып, мастерлар кабул итүе оештырып булыр иде, әмма пунктларны тотуга аренда бәяләре биредә күрсәтелгән хезмәт суммасыннан шактый артык. Өстәвенә һәр төр хезмәткә лицензия булдыруны да таләп итәләр. Шулай булгач, аларны тоту мөмкинлеге юк. Чөнки идарә һичнинди дотацияләрсез, үз исәбенә яши, производство бинаралы өчен дә, башка төрле налогларны да күп түләргә тиеш. Аңлашыла ки, түләү сәләте дә зур түгел. Үзенә бурычлы булганнардан да акчасын кайтарта алмый. Әнә, ике еллап элек Мәңгелек ут янындагы стелланы карап сокланган идек, әмма моңа көнкүрешчеләрнең кулы тиюе турында күпләребез белми дә калды. Идарә башкарылган эш өчен тиешле 100 миллион сумны һаман да кайтарта алмый. Югыйсә, иш янына куш булыр иде әле.

Авырлык белән булса да көн күрә көнкүрешчеләр. Былның ике аенда халыкка 100 миллион сумлык халык куллануы товарлары реализацияләнгән, 154 миллион 775 мең сумлык көнкүреш хезмәте күрсәтелгән. Димәк, күпме кеше көнкүрешчеләр хезмәтеннән файдаланган, күпме кеше шатланган, сөенгән. Димәк, базарны никадәр мактасак та, көнкүреш хезмәтенә мөрәҗәгать итмичә булмый.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Укымый калмагыз!

**Аның турында бөтен шәһәр сөйли дип кистереп әйтеп булмаса да, аны белүчеләр, алай гына да түгел, ярдәмен тоючылар шактый. Бер танышымның озак еллар җәфа чиктергән хроник бронхит авыруыннан дәваланганнан соң чиренең сизелерлек йомшаруы турында сөйләгәне бар. Организмы бернинди кодлаштыруларга да бирешмәгән З.ның Ермошкин сеансларыннан соң үзенең алкогольгә мөнәсәбәте тулысынча үзгәрүен дә күреп беләм.**

**- Минем кебек ихтыяр көче йомшак булган кешеләргә һич курыкмыйча Ермошкинга барырга киңәш итәр идем,- ди ул. - Аек килеш дөньяны бөтенләй икенче төрле итеп кабул итәсең бит...**

**- Остеохондроздан дәваланам. Берничә сеанс массаж алуга ук аркаларым йомшарды,- диде психотерапевт кабул итә торган бүлмәгә керү өчен чиратта торучыларның берсе.**

**- Астмадан да дәвалый дип ишеттем. Шуны белешергә килдем әле,- дип сүзгә кушылды олы яшьтәге бер хатын - кыз.**

# ТАБИГАТЬ КӨЧЕН БИРГӘЧ...

... Бүлмәдә талгын көй ишетелә. Әллә шуңа, әллә инде массаждан соң буыннары йомшарып киткәнгә, кушеткада йөзтүбән яткан хатын - кыз да үзен тыныч хис итә. Янәшәдәге ак халатлы төз гәүдәле ир - ат исә җиңелчә генә пациентның тәненә кагыла. Сеанс тәмамлануны искәртеп, музыка туктап кала.

- Бик зур рәхмәт сезгә, Александр Васильевич...

...Яшьли мавыгып спорт белән шөгыльләнгәндә, аның мәртәбәле төре - Көнбатыш көрәшен яхшы итеп үзләштергәч, үзендә әлегәчә тоймаган энергия барлыгын сизенде ул. Җанының бу халәте турында дуслары, якыннан таныш табибларына да әйтте. Ә алары исә аңа Мәскәүдәге традицион медицина үзәгенә барырга тәкъдим иттеләр. Александр тәвәккәлләде һәм шунда сайлап алу курсына укырга керде. Җанының шушы халәтен теоретик яктан өйрәнеп ул бер нәрсәгә төшенде: энергиясе шул кадәр күп икән, хәтта чит кешеләрне дәваларлык. Шулай булгач, ни өчен әле аңа файдалану тапмаска? Елына берничә тапкыр курсларга барып кайту аңа кеше физиологиясен, аның мөмкинлекләрен теоретик, шулай ук практик яктан да өйрәнергә мөмкинлек бирде. Ә инде 1993 нче елда Мәскәү шәһәренең баш медицина идарәсе каршындагы «Планетаны торгызу» халыкара ассоциациясе курсларын тәмамлап, кулына биоэнергетика буенча психотерапевт дипломы алгач, төп яшәү урыны - Көнбатыш Себердәге Урай шәһәрендә дәвалау эше белән шөгыльләнә башлый.

Торган җир никадәр генә матур булса да, туган җир сагындыра дип әйтү юкка гына түгелдер инде. Александр белән дә шулай булды. Шәһәр үзәгендәге бөтен уңайлыклары булган болын кадәре фатирын сатып, туган ягы - Татарстанның Октябрь районына кайтып китүенә дә шул сәбәп булды.

- Заманалар авырайды, бергә - бергә яшәү җиңелрәк булыр,- дип ышандырдылар бит туганнары. Аннары туган җире Якушкино туфрагының шифасы болай да гадәти булмаган көчкә ия Александрга яңа стимул, энергия өстәячәгенә ышана иде ул. Мәрхүмә әбисенә күз тиеп, сихергә очрап, дәваланырга килүчеләрнең терелеп китүләренә малай үзе шаһит иде бит. Вафатына шактый гомер үткән әтисе Василий Туймулловичның да буыннар каймыгып килүчеләрне кабул итүен күргәне бар иде. Димәк, Александрга да бу сәләт нәселдән килгән. Ә мондый шөгыльне «үстерүгә» кайчак һава да, басып йөргән туфрагыбызның да тәэсире булуын белә, моны теоретик яктан да үзләштерде ул.

Хәзер Александр Васильевичның эш урыны «Сельхозтехника» акционерлык җәмгыяте медицина пунктында. Лицензиясе бар, башка документлары да тәртиптә. Әлеге предприятиедә эшләүчеләрне ул бушлай кабул итә, ә читтән килүчеләр өчен психотерапевт кабул итүе түләүле.

Александр Васильевич остеохондроз, скалеоз, радикулитны дәвалаганда тибет массажы ысулын куллана.

- Мускулларның бөтен тамырларын «җылытып», сөт кислотасын һәм башка зарарлы матдәләрне чыгару гадәти массаждан күпкә отышлырак,- ди ул үзе бу турыда.

Мәкерле чир астманы дәвалаганда да тибет медицинасының алдынгы ысулларын куллану кирәк дип саный психотерапевт.

Пунктка йөрәк авырулы кешеләр дә килә икән. Кайчак теге яки бу нерв кысылган була. Берничә сеанс мануаль терапия үткәрүгә үк авыруның хәле сизелерлек яхшыра. Довженко ысулы буенча алкогольдән кодлаштыру да яхшы нәтиҗә бирә. Узган ел Ермошкинга мөрәҗәгать итүче сәрхүшләрнең 87 проценты «яшел елан» белән хушлашкан. Александр Васильевич үзе исә бу күрсәткечтән канәгать түгел.

- Кешене көчләп кодлаштырырга алып килү нәтиҗәле түгел. Ә инде аракыны ташларга теләге булган, әмма моның өчен ихтыяр көче җитмәүчеләр дәвалауга тиз бирешә,- ди ул моны аңлатып.

Пунктка сулыш юллары авыруларын дәвалау үтенече белән килүчеләр дә бар. Бал белән массажны тибет ысулы массажы белән чиратлаштырып, дарулардан башка үткәрә Ермошкин. Буыннар, кабыргаларны да дәвалый, тәмәке тартудан да кодлаштыра. Гомумән, үзенә мөрәҗәгать итүчеләрнең байтагын сәламәтләндерүгә көче җитә, кирәк булганда киңәшләр бирә, бер сүз белән әйткәндә, тупланган белемен, осталыгын эшкә җигә. Шул җәһәттән Александр Васильевичның кичләрен балалар - яшүсмерләр спорт клубында эшләвен дә өстисе килә. Ул җитәкләгән группада 160лап бала шөгыльләнә. Ә ни өчен әле үзенең икенче «сулышын» ачарга ярдәм иткән Көнчыгыш көрәше серләрен яшьләргә дә өйрәтмәскә.

- Яшьләр яшьли чыныгып үссен. Гомумән, барлык халыкның да сау - сәламәт булуын телим. Ә сәламәт тәндә сәламәт акыл булуы барыбызга да мәгълүм,- ди Ермошкин безнең белән саубуллашып. Ә коридорда аны пациентлары көтә иде.

**Р.ГИНЯЕВА.**



## Кичәге почтадан

### *Хатын - кызларны зурлап*

Кәкре Атау авылы үзешчәннәре, әниләр, апа - сеңелләр бәйрәменә багышлап зур концерт программасы әзерләделәр. Зал тулы халыкка бәйрәм котлавы белән «Чирмешән» КХАсы идарәсе исеменнән бригадир Рәшит Кәлимуллин мөрәҗәгать итте, хатын - кызларга изге теләкләрен җиткерде. Концерт программасын алып бару да аңа йөкләнгән иде. Авылда үзләренең күркәм хезмәтләре белән танылган, ире Габделхак абый кебек үк санитар сумкасы тагып сугышны башыннан ахырынача кичкән, лаеклы ялга чыкканчы авылда халык сәламәтлеген кайгырткан бүген Чаллы шәһәрендә яшәүче Мәүҗүдә апа Зәйнуллина, аның белән бергә эшләгән Нажия Гатауллина, Гамбәр Нигъмәтуллина, Галя Ремеслова апалар, аларга алмашка килгән Рәмзия Вәлиәхмәтова, Тәнзилә Кыямова, Фәридә Хәниева кебек яшьләр, берничә буын авылдашларга белем бирүдә көчләрен кызганмаган Миннегөл Вәлиева, Нажия Зарипова, Нурия Яруллина апалар, заманында рәсеме газета битләреннән төшмәгән, берүзенә 150шәр бозау карап, аларның һәркайсыннан 1000 - 1500әр грамм тәүлеклек үсеш алган Хәерлебанат Абдуллина һәм башка бик күп хатын - кызларны авыл үзешчәннәре үзләренең җырлары белән сәламләде. Баянчы һәм җырчы Рәфис Миннеханов, Румия Алиева, Хәмдия Гыйләҗева, Фәүзия Кәлимуллина, Илшат Кыямов, Рәшит Кәлимуллин, сәхнә ветераны Сәгадәт Алишева, Кара Күлдән Нәфисә Нигъмәтуллина, Райл Ишмаев, Нәфис Нигъмәтуллиннарның чыгышларын, Җәмил Галиевның биюен тамашачылар яратып кабул итте. Кайчандыр ерак Башкортостан якларыннан Кәкре Атауга килен булып төшкән, инде тәмам авылның үз кешесенә әверелгән Нәфилә Хөснуллина шигырьләр укыды. Клуб хезмәткәрләре Х.Гыйләҗева, Ф.Кәлимуллина, Р.Нурмөхәммәтовалар сәхнәгә онытылып баручы скетч жанрын алып чыгып тамашачыларның күңелен ачтылар. Язның тәүге бәйрәменә багышланган концерт һәркемнең күңеленә хуш килде.

**Ж.ШАКИРОВ,**
**хәбәрче.**

## Белдерүләр

### Сатабыз

**Спартак ур., 25 адресы буенча йорт. Кыйммәт түгел.**

***

**Суворов ур., 7 адресы буенча йорт.** Октябрьская ур., 18 адресы буенча теләсә кайчан мөрәҗәгать итәргә.

***

**Дача участогы һәм чанада дача йорты**. Адрес: Лермонтов ур., 47. Тел.: 5 - 18 - 71.

***

**Өйгә китереп бирү шарты белән шифер - табагы 16 мең сум; рубероид (15 метр) - төргәге 65 мең сум.** Адрес: Аксубай эшчеләр поселогы, 2 - 18 - 66. Лицензиябез: сер. А - 96 № 000173.

***

**Азык - төлек комбинаты янында гараж һәм кызыл кирпеч.** Тел.: 2 - 12 - 69.

***

**1996 елгы, 3500 км. йөргән ВАЗ - 21083.** Тел.: 5 - 18 - 52.

### Сатабыз яки алмаштырабыз

**Самара өлкәсенең Безенчук районы Ольгино совхозында хосусыйлаштырылган ике бүлмәле фатир сатыла яки Норлатта шундыйга ук алмаштырыла.**

Норлатта адрес: Кузнецов ур., 20.

### Алмаштырабыз

**Ашлыкка яки иткә - ГАЗ - 53кә яңа двигатель. Бәяләр килешү буенча.** Адрес: Самара өлкәсе, Кошка авылында автовокзал тирәсендә «Автозапчасти» кибете, тел.: 2 - 14 - 99.

***

**Базар тирәсендәге ике бүлмәле фатирны - Кормыш микрорайонында шундыйга ук.** Тел.: 5 - 21 - 37.

### Аттестат югалды

***Павел Егорович Иванов исеменә бирелгән АВ сер. № 022133 аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.***

### Рәхмәт белдерәбез

Безнең өчен кадерле ул, ир, абый һәм әти булган Разыйх Хасыйбулла улы Мостафинны соңгы юлга озатуда мораль һәм матди ярдәм күрсәткәннәре өчен НУРБ, салым инспекциясе коллективларына, туганнарга, дусларыбызга һәм танышларыбызга ихлас рәхмәтебезне белдерәбез.

**Мәрхүмнең туганнары.**



## Вакытлы матбугатка язылу бара

# 1 апрельгә кадәр генә!

Татарстан Республикасы Элемтә министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, 1 апрельдән 1997 елның икенче яртыеллыгына газета - журналларга язылу башлана. Билгеле, яңа, күтәренке бәяләрдән.

Элемтәчеләр белән бергәләп фикер алышканнан соң, «Ватаным Татарстан» редакциясе үз газетасына язылучылар өчен ташлама, льгота ясарга булды. Хикмәт шунда: икенче яртыеллыкка иске бәяләр белән «Ватаным Татарстан» газетасына инде март аенда ук язылырга мөмкин. Димәк, сез бүген үк 1997 елның икенче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына иске бәядән язылa аласыз. 54123 индексы буенча гомуми язылу бәясе 42 мең 600 сум, 54211 индексы буенча (пенсионерлар өчен) 40 мең 800 сум. Кабат исегезгә төшерәбез: бу бәяләр 1 апрельгә кадәр генә сакланачак.

Димәк, газетабызның хөрмәтле укучыларына бүген үк элемтә бүлекләренә ашыгырга гына кала.

**И.ДИНДАРОВ,**
**газетаның үз хәбәрчесе.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә. Заказ № 6026